Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче Кече Җирекле торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елның 02 декабре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлегенең Кече Җирекле торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге Кече Җирекле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр balигъ булмаган яшәүчедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның хатыннары/ирләреннән тыш, 1000 сум күләмендә 2025 елда үзара салым кертергә. 2нче төркем инвалидлар һәм 80 яшьтән өлкәнрәкләр 50 % күләмендә түлиләр.
2. Алынган акчаларны су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау өчен юнәлдерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Каенлы авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гарипов